СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 21 » декабрь 2018 ел** **№ 79**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлегендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына таянып, гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Урта Курса авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Урта Курса авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендәге 70 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халык тыңлаулары халык, Урта Курса авыл җирлеге Советы (алга таба - Совет), Урта Курса авыл җирлеге башлыгы (алга таба - башлык) яисә контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә.

2) 5 статьяның 1 өлешендәге 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урта Курса авыл җирлеге башлыгы яки контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә торган гавами тыңлаулар Урта Курса авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә».

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина